# БАЛАЛАРНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕГЕН САКЛАУ.

Балаларының сәламәтлеген саклау, ныгыту хәзерге көндә ата-аналарны, педагогларны иң борчыган мәсәләләрнең берсе. Шуннан чыгып үз алдыбызга түбәндәге мәсьәләләрне куйдык:

- хәрәкәт - бала өчен иң кирәкле шарт булуын күз уңында тотып, бакчада хәрәкәтле уеннарны үз югарылыгында уздыру;
- туклану - бала организмы өчен иң мөһиме шарт, шуңа күрә менюны сәламәтлекне саклау технологиясенә нигезләнеп төзү;
- организмны чыныктыру нәтиҗәсендә баланың салкынга, эссегә, авыруларга каршы торучанлыгын арттыру, чыныктыруны һәр балалның үзенчәлекләрен искә алып оештыру;
- балаларның бакчадан тыш вакытын дөрес оештыру буенча ата-аналар белән әңгәмәләр үткәрү;
- мәктәпкәчә яшьтәге балачак - сабыйның психик үсешендәге беренче чор, чөнки бу яшьтә шәхеснең бөтен психик сыйфатларына һәм үзенчәлекләренә нигез салына. Шуларны истә тотып, баланың һәрьяклакп үсеше өчен гаиләнең тәрбияче белән үзара аңлашып, ярдәмләшеп эшләвен булдыру.

Кыскасы, балаларны сәламәт рухта тәрбияләү – балалар бакчасының изге бурычы, чөнки балаларның күп вакыты бакчада уза, ул аларның икенче өе булып тора. Шунлыктан бакчада нәниләр өчен барлык уңай шартларны тудырырга тырыштык. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм интеллектуаль үсешен тәэмин итү йөзеннән, эшебезне планлаштырудан башладык, планнарны балалар бакчасының эшен камилләштерү буенча үзгәрешләр кертеп һәм яңа бурычлар куеп оештырдык. РЦБ педиатры тарафынан балаларны тикшерү үткәрелде. Тәрбиячбез көндәлек режимны төгәл үтәп, белем-тәрбия бирү эшен дөрес оештырды. Иртәнге гимнастика, физкультура занятиеләре ел буена программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барылды. Физкультура дәресләрендә иң беренче балаларның активлыгына игътибар ителде, дәрес уздыру төрләре үзгәртелде, яңалыклар кулланылды.

Бакчада физкультура дәресе зурлар төркемендә өч тапкыр уздырылды - дәреснең берсе, һава торышы уңай булганда, ачык һавада узды. Дәресләрдә түбәндәге мәсьәләләрне тормышка ашырдык:

- балаларның үсешенә һәрвакыт игътибарлы булу;
- балаларга тормышта кирәкле хәрәкәт күнекмәләре бирү;
- сәламәтләндерү, чыныктыру эшенә шартлар булдыру;
- балаларның сәламәтлекләрен ныгыту, көчен, җитезлеген үстерү;
- сәламәтләндерү юнәлешендә төрле физик күнегүләр белән даими шөгыльләнүгә ихтыяҗ булдыру;
- заман таләпләренә туры килгән прграммалар куллану, яңалыкка омтылу.

Грипп, ОРЗ чорында медсестра группада сарымсак инголяциясе ясады. Группа тәрбиячесе сарымсактан төймә ясап, балаларга тактылар. Эшебезнең нәтиҗәсе - грипп эпедимиясе вакытында бакча карантинга ябылмады, авыручы балалар саны да аз булды.

Чыныктыру, сәламәтләндерү процедураларын башкарганда тәрбияче түбәндәге гигиена шартларын һәм таләпләрен төгәл үтәде:

- бүлмә һавасының саф булуы;
- бинадагыһава температурасының нормада булуы;
- киемнәрнеңһава температурасына карап дөрес сайлануы;
- активхәрәкәт режимы.

Бу юнәлештәге эшнең нәтиҗәсе ата-аналардан да бәйле. Без аларга сәламәт яшәү рәвешен формулаштыру принципларын өй шартларында да үтәү кирәклеген искәртеп тордык.

Менюда ризыклар төрләндерелде, балалар аксымга бай продуктлар, үз бакчабызда үстерелгән яшелчә, ел әйләнәсендә җиләк-җимеш белән тукландырылды.

Дөрес туклану, көндәлек режимны, физкультура, спорт белән даими шөгыльләнү, организмны чыныктыру балаларыбыз сәламәтлегенә уңай тәэсир итте: алар азрак авырды.